ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 16.08.2024 1246 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтиярый ярдәм итү (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек Тәртибен раслау турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 1681 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 7 вгустындагы 394-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» Федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 340-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга, ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек Тәртибен раслау турында» 2018 елның 23 ноябрендәге 1681 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 21 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итү рәвешләрен гамәлгә ашыра.

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

1) финанс ярдәме, шул исәптән грантлар һәм субсидияләр бирү;

2) оештыру ярдәме;

3) мәгълүмати ярдәм;

4) консультация ярдәме;

5) мөлкәти ярдәм, шул исәптән биналарны түләүсез файдалануга бирү;

6) методик ярдәм.

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы» Федераль законның 17.4 статьясының 2 пунктында каралган, ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чаралары исемлеге, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан рәвешләрне исәпкә алып билгеләнә.

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярыйлык (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы» Федераль законның 17.5 статьясының 2 пунктында каралган, әлеге ярдәм итү чаралары турында мәгълүмат ихтыярыйлык (волонтерлык) үсеше өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында Тәртип нигезендә урнаштырыла.

Коммерциячел оешмалар булган ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга финанс һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү рөхсәт ителми.».

1.2. Тәртипнең 3 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүдә, янгыннарныкисәтүдә һәм сүндерүдә, авария-коткару эшләрен үткәрүдә, шулай ук табигатьафәтләре, экологик, сәнәгать яки башка катастрофалар, социаль, милли, диниконфликтлар нәтиҗәсендә зыян күргәннәргә, репрессия корбаннарына, качакларгаһәм мәҗбүри күченүчеләргә ярдәм күрсәтүдә катнашу; халыклар арасындатынычлыкны, дуслыкны һәм татулыкны ныгытуга, социаль, милли, диниконфликтларны булдырмауга ярдәм итү;».

1.3. Тәртипнең 3 пунктын түбәндәге абзацлар белән тулыландырырга:

« -хәбәрсез югалган затларны эзләүдә гражданнарның катнашуы;

-медицина ярдәме күрсәтелә торган медицина оешмаларында медицина ярдәме күрсәтүдә ярдәм итү;

-Россия Федерациясе законнары нигезендә эчке эшләр органнарына (полиция)һәм башка хокук саклау органнарына җәмәгать тәртибен саклауда ярдәм итү;

- Ватанны саклаганда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү

буенча чаралар үткәрүдә катнашу;

- чит илдә яшәүче ватандашларга аларның хокукларын гамәлгә ашыруда, аларның мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүдә һәм гомумроссия мәдәни үзенчәлеген саклап калуда ярдәм күрсәтү».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева